Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

13 ноябрь, 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Кәвәл авыл җирлеге Кәвәл авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә:

Халык җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2019 елның 30 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Мәктәп урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет, Пионер, Яшел урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2019 елның 7 декабрендә 11 сәгать 00 минутта Мәктәп урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Киров, Яңа, Мәктәп, Үзәк, Тукай урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Кәвәл авыл җирлеге Кәвәл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларны һәм мәктәп укучыларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кәвәл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Фәйзрахманов